| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МАЛОМЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.01.2022 Кече Мәми ав. № 39

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Советының 31.10.2019 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2021 елның 01 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау турында» 31.10.2019 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә (27.02.2020 №3, 08.06.2020 №8, 08.10.2020 №5 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 27 статьяның 27 пунктын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Кредит (облигациядән тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия кредит килешүендә (заем килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне кредитор (заем) йөкләмәләрен бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән кредит (заем) акчаларыннан максатчан файдалануны үз ягыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыру шарты белән бирелә.»;

1.2. 32 статьяда:

2 пунктны түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясенең милли үсеше максатларын һәм гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү юнәлешен билгеле торган документлар;»;

өченче - бишенче абзацларны дүртенче - алтынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://mmemin-kaybici.tatarstan.ru/ веб - адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Кече Мәми авыл җирлеге Башлыгы Е.Н.Алексеевна